**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.07.2018 № 587

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында автомобиль транспорты белән даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында нигезләмә раслау хакында” 2016 елның 19 августындагы 544 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль законны гамәлгә ашыру турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 2018 елның 11 апрелендәге 22-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында автомобиль транспорты белән даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында нигезләмә раслау хакында” 2016 елның 19 августындагы 544 санлы карары (2018 елның 24 апрелендәге карары редакциясендә) белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы

муниципаль районында автомобиль транспорты белән даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында” Нигезләмәгә (алда – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 10.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10.3. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрларына кертелгән белешмәләр (индивидуаль эшкуарның яшәү урыны турындагы белешмәләрдән тыш) мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырыла.”;

1.2. Нигезләмәнең 1.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.5. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы белән кыскарак сроклар килештерелмәгән булса, бу маршрутны билгеләгән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты инициативасы белән мендый таныклык гамәлдә булган чор дәвамында тиешле маршрутны үзгәртү йә туктату турында карар мондый таныклыкның гамәлдә булу чоры тәмамлану көненә кадәр 180 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә һәм әлеге таныклыкның гамәлдә булу чоры тәмамланганнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы Башкарма комитеты тарафыннан даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутын үзгәртү турында әлеге Нигезләмәнең 1.5 нче пунктында каралган карар кабул ителгән көннүн алып 60 көн дәвамында шушы маршрут буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хакында таныклыклар бирелгән юридик зат, индивидуаль эшкуар, гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетына кабул ителгән карар нигезендә мондый таныклыкларның һәм шушы маршрут карталарының гамәлдә булуын киләсе срокка озайту турында гаризалар белән мөрәҗәгать итәргә тиеш.”.

2. Әлеге карарны мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар, әлеге карарның 2018 елның 28 июненнән көченә керәчәк 1.1 нче подпункттыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Җитәкче Р.В. Михеев